

Минем бабам – Хәбибулла Нуруллин Татарстанда кечкенә генә Кармыш авылында кvп балалы гаиләдә туып-vсә. Ул малайлардан ин кечесе була. Әле балачактан ук очучы булырга хыялланган егет 18 яше тулгач та, очучылар әзерли торган хәрби училищега укырга китә. Инде укуын бетергәндә генә, илебезгә фашист илбасарлары басып керә. Шулай итеп, кичә генә хәрби очучы таныклыгын алган егет, vзенен очкычына утырып, дошман истребительләренә каршы корәшә башлый.
Показать полностью..

Бик кvп немец самолетларын жәһәннәмгә олактыра ул. Бу батырлыгы очен аны орден белән бvләклиләр. Бервакыт ул самолетында кvккә кvтәрелеп, vзенен хәрби бурычын vтәгәндә, фашист минасы анын кабинасына тия. Ул vзе дә каты яралана. Хәбибулла Нуруллин коч-хәл белән парашютында янган самолеттан жиргә сикерә. Бәхетенә, тошкән жире безнен жир була!

Бик каты яраланган, анын югалткан бу яшь очучыны безнен сугышчылар кырда табып алалар һәм госпитальгә озаталар. Баш миенә каты зарар килгәнгә, ул кvп айлар госпитальдә ансыз ята. Анына килгәч тә, vзенен кем икәнлеген, исем-фамилиясен, кайдан булуын хәтерли алмый.

1945нче елнын 9 Маенда бу каһәр суккан сугыш безнен Жинv белән тәмамлана. Совет солдатлары торкем-торкем булып сугыштан ойләренә әйләнеп кайта башлыйлар. Хәбибулланын бу вакытта авылда яшәгән әти-әниләре дә кече уларын сугыштан зур тvземсезлек белән котәләр. Аларнын ике олы уллары әле 1943-44 елларда ук сугыш кырында һәлак булалар. Сугышка киткән 4 уларынын уртанчысына гына туган авылына жинvче булып кайту бәхете тия, ә менә очучы уларыннан бернинди хәбәр дә килми картларга. Инде котеп-котеп тә, кече уллары кайтмагач, алар хәрби архивка һәм тагын әллә нинди жирләргә хатлар жибәрәләр. Тик барысы да юкка була. Аны хәбәрсез югалганнар арасында да, һәлак булганнар арасында да тапмыйлар. Шулай уллары турында берни белмичә vлеп китәләр анын ата-анасы...

Сугыш тәмамланып, инде 40 еллар чамасы vткәч, Хәбибулланын хәтере кайта, һәм ул vзенен кем икәнлеген, исем-фамилиясен, кайдан булуын исенә тошерә. Тиздән чал чәчле, кvкрәге тулы орден-медальле фронтчы, элеккеге хәрби очучы, хәрби пенсионер, сугыш ветераны Хәбибулла Нуруллин Кармыш авылына кайтып тошә. Юлдан ул туп-туры шушы авылдагы колхоз правлениесенә, колхоз рәисенә килә һәм vзенен авылдагы туганнары турында сораша. Шулай итеп, кечкенә абыйсынын vз гаиләсе белән монда яшәвен белә. Рәис тарафыннан бирегә чакырылган абыйсы алдан бу хәбәргә ышанмаса да, правлениегә тиз арада ашыга-ашыга килеп тә житә. Шунда бик озак эзләп тә,

табалмаган, жанына шулкадәр якын булган, кvкрәге тулы орден-медальле чал чәчле ир-атны кvреп, алдан беравык дәшмичә тора, аннары елый-елый Хәбибулланы кочаклап ала. Бу дулкынландыргыч очрашунын шаһиты булган житәкченен исе китә: туганнар бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган булалар.

Сонрак, абыйсынын оендә, табын янында ашап-эчкәч, югалган энекәше абыйсына vзе турында кичергәннәрен сойләп бирә.

Янган самолетыннан каты яраланган килеш парашюттан жиргә сикереп, анын югалтканнан сон, безнен солдатларнын аны табып, госпитальгә илтvләре турында сойли ул. Бу хәлдән сон ана бик озак вакытлар торле госпитальләрдә, хастаханәләрдә, хәрби шифаханәләрдә дәваланырга туры килә. Санаторийларнын берсендә ул vзен дәвалаган шәфкать туташына гашыйк була һәм ана кияvгә чыгарга тәкъдим ясый. Шуннан сон яшь гаилә Краснодар краенын Горячий ключ шәһәрендә яши башлый. Озакламый анын улы һәм кызы туа. Тормыш әкренләп vз жае белән алга таба бара башлый. Инде балалары да vсеп, vз тормышлары белән яши башлыйлар.

Хәтер дигәнен генә хужасына әйләнеп кайтырга ашыкмый шул. Тик бервакыт анын белән бер сәер хәл була. Жәен ул гаиләсе белән Кара дингезгә ял итәргә китәргә жыена. Әле кvптән тvгел генә яна жинел машина алган Хәбибулла рульгә vзе утыра. Юлда аларнын машинасы авариягә эләгә һәм ул башы белән рульгә бәрелеп, анын югалта. Аны ашыгыч ярдәм кvрсәтv машинасы шәһәр хастаханәсенә илтә. Инде палатада ул анына килә һәм vзенен исем-фамилиясен, кем һәм кайдан булуын исенә тошерә. Шул минуттан алып, ул туган якларын, туганнарын кvрv теләге белән янып йори башлый. Ниһ аять, авылдан 18 яшендә чыгып китеп, 40 ел туган жирләрен кvрмәгән чал чәчле карт бабам туган авылына кайту бәхетенә ирешә. Хәбибулла бабай абыйсында берничә кон кунак була. Шушы коннәрдә ул vзенен туганнары, вафат булган әти-әниләре турында да кvп нәрсә белә, кvп жирләрдә була. Аннары vзе, анын гаиләсе, балалары яшәгән Горячий ключ шәһәренә кайтып китә. Тик кvнелен, vзенен яралы, кvпне кичергән йорәген туган авылында калдырып китә. Инде 40 елдан сон табылган ир-туганын калдырып, ансыз яши алмавын сизгән бабам, берникадәр вакыт vткәч, vзенен туган Кармыш авылына әйләнеп кайта һәм шунда абыйсынын кулында vлә.

Шулай итеп, немец фашистлары башлаган бу каһәр суккан сугыш кvпме кешеләрнен язмышлары, тормышлары белән уйнаган, кvпме кешеләрнен гомерләрен койдергән икән?!

Хәбибулла бабам - авыр, катлаулы, фажигале тормыш юлларын кичергән гади татар авылы малае, хәрби очучы, медальләргә лаек булган, кvп илләр кvргән, 40 ел буе vзенен кем икәнлеген белмичә яшәгән сугыш ветераны. Ул кvп санлы орден-медальләргә лаек булган, кvп илләр кvргән. Ә менә гомеренен сонгы айларында vзенен газиз туган якларына, туган авылына, туганнары янына кайтып vлvне һәм анда авыл зиратына жирләнvне олы бәхет итеп санаган.

Самар шәһәре “Яктылык” мәктәбенен 8 сыйныф укучысы
Нариман Мәксvтов.

(Информация предоставлена Нурзидой Ахметовной Файзуллиной)